**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 елның «31» маеннан № 226

**«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 24 ноябрендәге 504 номерлы карары белән расланган «2015-2020 елларга Яңа Чишмә муниципаль районының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»**

«2015-2020 елларга Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы карары белән расланган «2015-2020 елларга Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 26 маендагы 354 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 24 ноябрендәге 504 номерлы карары белән расланган «2015-2020 елларга Яңа Чишмә муниципаль районының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Программа паспортынның «Программаны (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) гамәлгә ашыруның көтелә торган һәм ахыргы нәтиҗәләре»ндә сигезенче абзацны төшереп калдырырга;

- Программаның 1 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Программа җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр, оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырыла торган, Яңа Чишмә муниципаль районында коррупцияне кисәтү, коррупция бозуларны минимальләштерү эшендә конкрет

нәтиҗәләргә ирешүгә юнәлдерелгән хокукый, мәгариф, тәрбия, оештыру һәм башка чараларны килештереп куллануны тәэмин итә торган комплекслы чаралар системасыннан гыйбарәт»;

- Программага кушымтада:

1.2.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «1.2.2. Муниципаль хезмәткәрләрнең чикләүләрне һәм тыюларны, шул исәптән Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең «Юридик затларның бердәм дәүләт реестры» һәм «Индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестры» мәгълүматлар базаларыннан файдаланып, эшмәкәрлек эшчәнлегендә катнашу предметын, муниципаль хезмәт тәртибенә карата законнарда каралган чикләүләрне һәм тыюларны үтәүләрен тикшерү ( кимендә елына бер тапкыр) | Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының кадрлар секторы мөдире, Яңа Чишмә районы прокуратурасы (килешү буенча) | 2015-2020 еллар | | | | | | | | | - | - | - | - | - | -»; |

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «1.3. Коррупциягә каршы көрәш буенча эшне координацияләү комиссиясе эшчәнлегенең ачыклыгын тәэмин итү, шул исәптән алар эшчәнлегенә иҗтимагый советлар һәм гражданлык җәмгыяте институтларын җәлеп итү юлы белән дә тәэмин итү | Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ярдәмчесе (килешү буенча), (килешү буенча) | 2015-2020 еллар | | | | | | | | | - | - | - | - | - | -»; |

түбәндәге эчтәлекле 1.3.1 пункт белән тулыландырырга:

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «1.3.1. Яңа Чишмә муниципаль районында коррупциягә каршы тору буенча эшне координацияләү буенча комиссиянең еллык эш планнарын | Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ярдәмчесе (килешү буенча), (килешү буенча) | 2016–2020 еллар | Комиссия утырышлары саны елына | | | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | - | - | - | - | - | -»; |

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| раслауны һәм алга таба үтәүне тәэмин итү | | | | | | | | | | | | | | | | |

4.6 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «4.6. Муниципаль хезмәткәрләрнең чикләүләрне, тыюларны үтәү буенча эшен оештыру, аңлату һәм башка чаралар комплексын тормышка ашыру, шулай ук коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән бурычларны, шул исәптән бүләкләр бирү һәм алуга кагылышлы чикләүләрне, әлеге эшкә Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнары каршындагы иҗтимагый советларны, коррупциягә каршы торуда катнашучы иҗтимагый оешмаларны һәм гражданлык җәмгыятенең башка институтларын җәлеп итеп, башкару буенча чаралар комплексын тормышка ашыру | Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының кадрлар секторы мөдире, Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ярдәмчесе (килешү буенча), (килешү буенча) | 2015-2020 еллар | | | | | | | | - | - | - | - | -»; |

5.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «5.11. Вазыйфаи затлар эшчәнлегендә коррупция күренешләре турында массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштырылган һәм гражданнар һәм юридик затлар мөрәҗәгатьләрендә булган мәгълүматка мониторинг үткәрү эшен оештыру, квартал саен гомумиләштерү һәм аның нәтиҗәләрен Яңа Чишмә муниципаль районында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе утырышларында карау | Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ярдәмчесе (килешү буенча), (килешү буенча) | 2015-2020 еллар | | | | | | | | - | - | - | - | - | -»; |

түбәндәге эчтәлекле 9.13, 9.14 пунктлар өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «9.13. Коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән тыюларны, чикләүләрне һәм таләпләрне үтәмәгән очракта, законнарда каралган юридик җаваплылык чараларын куллануны контрольдә тотуны гамәлгә ашыру | Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты эшләре белән идарә итүче;<br>Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ярдәмчесе (килешү буенча),<br>.<br>Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының кадрлар секторы мөдире | 2016–2020 еллар | | | | | | | | | - | - | - | - | - | -»; |
| «9.14. Муниципаль хезмәттә мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу турындагы закон таләпләрен үтәүне тәэмин итү | Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының кадрлар секторы мөдире | 2016–2020 еллар | | | | | | | | | - | - | - | - | - | -»; |

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә (бастырып чыгарырга).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр белән идарә итүчесенә йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Р.Р. Фасахов**